ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**15.11.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3574**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 19 маендагы 870 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче Зеленодольск муниципаль районы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә – хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар хисабына, акчалата түләүләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 18 ноябрендәге 1234 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 19 маендагы 870 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче Зеленодольск муниципаль районы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә – хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар хисабына, акчалата түләүләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта икенче абзацта «1 111» саннарын «2 510» саннарына алмаштырырга;

9 пунктта бишенче абзацта «1.111» саннарын «2 510» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны

Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкче урынбасары, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручыга йөкләргә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин